# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле рәвештә «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

1 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү чараларын Татарстан Республикасының республика бюджетын үтәгәндә өстәмә алынган керемнәр исәбеннән финанслау максатларында «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998 ел, №12; 1999 ел, №6) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1999 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын керемнәр буенча 13197103 мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 13839256 мең сум күләмендә расларга.

1999 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 642153 мең сум күләмендә билгеләргә.».

2. 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасының республика бюджетына агымдагы чыгымнарны финанслау өчен ассигнованиеләрнең гомуми күләмен - 8044384 мең сум дип, үсеш бюджетын финанслау өчен, капитал салуларны да кертеп, 5794872 мең сум, дип билгеләргә.».

22 статьяның 1 абзацындагы 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт хакимиятенә һәм идарәсенә, 224583 224583».

4. 25 статьяда:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1999 елга дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны 224583 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең, | 7566 |
| шул исәптән: | |
| киткәннәре урынына Татарстан Республикасының яңа халык депутатларын сайлауларны үткәрүгә | 800 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә | 4766 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә | 1200». |

5. 43 статьяга түбәндәге сүзләрне өстәргә: «Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү чыгымнары».

2 статья. Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көннән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2340